РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЙБИЦКОГО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.01.2026 ел № 1-8

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының
Кайбыч авыл җирлегендә бюджет процессы
турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 4 августындагы 416-ФЗ номерлы, 2023 елның 25 декабрендәге 628-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законнар нигезендә Буа муниципаль районы Кайбыч авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кайбыч авыл җирлегендә бюджет процессы турында «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кайбыч авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 16 июлендәге 2-46 номерлы нигезләмәгә ( 12.05.2020№ 86-1, 19.08.2020 94-2, 20.10.2020 № 2-4, 14.09.2021 № 28-1, 13.10.2021 31-1, 08.04.2022 №46-1, 18.07.2022 № 53-1, 13.07.2023 №1-75, 21.05.2025 №3-98 карарлары ред.) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 5 статьяның 8 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

әлеге кодексның 221 статьясы нигезендә билгеләнә торган тәртиптә бюджет сметасын төзи, раслый һәм алып бара.

1.2. 16.1 статьяның 5 пунктында «билгеләнгән тәртиптә» сүзләрен «билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда» сүзләренә алыштырырга, «иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең «Электрон бюджет» дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасын кулланып, әлеге пунктта каралган очраклардан тыш, гавами-хокукый берәмлекнең бюджеттан акчалар бирү буенча йөкләмәләре күләмен тикшерү максатларында» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм җирлекнең рәсми сайтында Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырылырга тиеш. http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районы
Кайбыч авыл җирлеге башлыгы С.И.Нуретдинова